| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ХОЗЕСАНОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ХУҖА ХӘСӘН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05 июль 2023ел Хуҗа Хәсән ав. №13

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы **Хуҗа Хәсән** авыл җирлеге Советының 2020 елның 07 июлендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы **Хуҗа Хәсән** авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге Советының 2020 елның 07 июлендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) (алга таба – Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 4 пунктта, 5 пунктындагы 2 абзацында, 6 пунктның 1 абзацында, 7 пунктның 1,3 абзацларында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 11 пунктның 1 абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Хуҗа Хәсән авыл җирлеге мәгълүмат

стендларында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Хуҗа Хәсән авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Хуҗа Хәсән авыл җирлеге
Башлыгы С.П.Матвеева